**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге Ютазы торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында

**«04» декабрь 2020 ел** **№6**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»ГЫ 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2020 елның 3 декабрендә, 2020 елның 4 декабрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2021 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Малиновка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I һәм II төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрүгә сез ризамы:

1) Ютазы торак пунктының Вахитов, Комсомольская, Ворошилов урамнарындагы юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (асфальтлау, юллар һәм тротуарлар төзү, төзелеш материаллары сатып алу, таш ташу, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Ютазы торак пунктын төзекләндерү ( коры агачлар, куакларны кисү, территорияне җыештыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 1591 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 811 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 811 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ютазы торак пунктында халык җыены узган, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип санарга.

2. "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Ютазы торак пункты территориясендә һәр балигъ булган кешедән, I һәм II төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш, 2021 елда үзара салым кертүгә 400 сум күләмендә акча кертү белән килешәсезме?:

1) Ютазы торак пунктының Вахитов, Комсомольская, Ворошилов урамнарындагы юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (асфальтлау, юллар һәм тротуарлар төзү, төзелеш материаллары сатып алу, таш ташу, салу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Ютазы торак пунктын төзекләндерү ( коры агачлар, куакларны кисү, территорияне җыештыру, килешү буенча эшләр өчен түләү) - карарын кабул ителгән дип санарга.

3. Җыелышның нәтиҗәләрен Ютазы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru, хокукый мәгълүматның рәсми

сайтында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Р.М.Галимов